# Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында
# ХӘБӘР ИТҮ

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында шушы мәгълүмат белән хәбәр итәбез.

<u>Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:</u>

1) Территориаль планлаштыру турында нигезләмә;
2) Торак пунктлар чикләре урнашу урыны тасвирламасы;
3) Функциональ зоналар картасы.

<u>Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм сроклары:</u>

Ачык тыңлаулар 16.09.2025 елдан 04.10.2025 елга кадәр үткәрелә һәм түбәндәге этапларны үз эченә ала:

- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;
-гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проектның экспозициясен яисә экспозицияләрен ачу;
-проект экспозициясен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

<u>Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:</u>

- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Писмән авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Писмән авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарның хокук ияләре.

Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә Подлесный бистәсе, Дурасово авылы, Иске Писмән авылы, Восход авылы, Савочкино авылы, Югары Каран бистәсе, Воздвиженка бистәсе, Дала Зәе бистәсе торак пунктларында үткәрелә.

2025 елның 16 сентябреннән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлегенең гавами тыңлауларда каралырга тиешле генераль планы проекты экспозициясен авыл җирлеге администрациясе бинасында ачарга: ТР, Лениногорск муниципаль районы, Подлесный бистәсе, Гагарин ур., 5 й.

Проект экспозициясен үткәрү сроклары: 16.09.2025 - 04.10.2025

Проект экспозициясе белән танышу вакыты – 9.00 дән 11.00 гә кадәр һәм 14.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр дүшәмбедән җомгага кадәр.

Гавами тыңлауларда катнашучыларга генераль план проектына кагылышлы үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен язма рәвештә, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге адрес буенча кертергә тәкъдим итәргә: ТР, Лениногорск муниципаль районы, Подлесный бистәсе, Гагарин ур., 5 й. яисә Pism.Len@tatar.ru, яисә 2025 елның 30 сентябрендә гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү барышында проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу журналына язма рәвештә яисә телдән язып куюю юлы белән..

Язма рәвештә тәкъдим ителгән искәрмәләргә һәм тәкъдимнәргә документларның күчермәләре дә кушып бирелергә тиеш: физик затлар өчен яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга куелган һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2014 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләр нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү турында документның күчермәсе; юридик затлар өчен - ЕГРЮЛдан өземтә.

Экспозиция эше барышында "Писмән авыл җирлеге"муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына экспозициягә килүчеләргә консультацияләр бирергә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын билгеләргә:

30 сентябрь 2025 ел 17.30 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Подлесный бистәсе, Гагарин ур., 1б;

2025 елның 16 сентябренә кадәр боерык проектын рәсми сайтта түбәндәге адрес буенча : https://leninogorsk.tatarstan.ru/ «Авыл җирлекләре»бүлегендә урнаштырырга.

Әлеге хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырырга:

- Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Подлесный бистәсе, Гагарин ур., 5 й.;

-Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Писмән ав., Үзәк ур., 50 й.;

- Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Савочкино ав., Урман ур., 49а й.;

- Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Дурасово ав., Төньяк ур., 2 й.;

- Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Югары Каран бистәсе, Югары ур. (кергәндә);

- Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Дала Зәе бистәсе, Дала зае ур., 23 й.;

- Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Воздвиженка бистәсе, Түбән ур., 8 й.;

- Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Восход ав., Крупская ур., 5а йорт.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Дементьев Н.В.